**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 25 декабрь № 982

г. Казань

«П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен һәм «Казан машина төзелеше техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләрне һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын күтәрү, кадрларны әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте) аңарга «Казан машина төзелеше техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – Казан машина төзелеше техникумы) кушу юлы белән, П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятенең төп эшчәнлек максатларын саклап, үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятен гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятен гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнарда күздә тотылган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы таләпләрен саклап, Казан машина төзелеше техникумында укучыларны ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, укыту шартларын һәм программаларын саклап, П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятенә күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

30 көн эчендә түбәндәгеләргә тиешле үзгәрешләрне кертергә:

П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте уставына;

П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Казан машина төзелеше техникумының оператив идарә хокукында П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятенә бирелергә тиешле мөлкәте исемлеген, шулай ук Казан машина төзелеше техникумына оператив идарә хокукында беркетелгән күчемсез мөлкәттән алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 60 көн эчендә Казан машина төзелеше техникумына элек оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятенә законнар белән билгеләнгән тәртиптә бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте уставы үзгәрешләрен дәүләт теркәвенә алганнан соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларын торак урыннар белән тәэмин итүгә нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2015 ел, 16 октябрь, 776 нчы карарына аны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\982.doc